ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МӘМӘШИР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

2020 елның 28 январе 3 номерлы

Мәмәшир авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2013 елның 22 ноябрендәге 28 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Мәмәшир авыл җирлеге карар бирде:

1. «Җир салымы турында» 2013 елның 22 ноябрендәге Мәмәшир авыл җирлеге Советының 28 номерлы карарына (Мәмәшир авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 40 номерлы, 2015 елның 27 маендагы 24 номерлы, 2015 елның 17 ноябрендәге 13 номерлы, 2017 елның 27 июнендәге 11 номерлы, 2018 елның 29 ноябрендәге 32 номерлы, 2018 елның 29 ноябрендәге 32 номерлы, 2018 елның 17 декабрендәге 35 номерлы, 2019 елның 28 ноябрендәге 21 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) кадастр хакының 0,1% ы – 2017 елның 29 июлендәге «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: www.pravo.tatarstan.ru, шулай ук Мәмәшир авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында да.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы: И. Г Әхмәтҗанов

ОГРН 1021607753012
ИНН 1623001702